ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«12» октября 2018 ел № 975

**"Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен" премиясе турында**

"Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында" 2015 елның 16 гыйнварындагы 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Арча муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. 1 нче кушымта нигезендә "Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен" премиясе турында нигезләмәне (алга таба-премия);

1.2. 2 нче кушымта нигезендә "Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен" премиясен бирү буенча комиссия составын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:\\pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«__» ________ 2018 ел, N ____
карарына 1 нче кушымта

**"Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен" премиясе турында нигезләмә**

1. "Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен" (алга таба - премия) премиясе җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы Арча муниципаль районы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатында бирелә.

2. Премияне бирү ярты ел нәтиҗәләре буенча елга ике тапкыр башкарыла.

Премия егерме премия күләмендә бирелә.

3. Премияне бирү өчен Татарстан Республикасында халык дружиналары һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр реестрына кертелгән, җәмәгать тәртибен саклауда катнашкан халык дружиналары әгъзалары кандидатлар булып тора.

4. Халык дружинасы отряды командиры премия бирү өчен кандидатны тәкъдим итүне яртыеллык тәмамланырга 10 көн кала әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендәге форма буенча комиссиягә җибәрә.

5. Комиссия үз утырышында кандидатларның тәкъдимнәрен карый һәм премия бирү турында карар кабул итә.

6. Комиссия үз утырышларына хокук саклау органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен чакырырга хокуклы.

7. Премияне бирү турындагы карар комиссия утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

8. Карар кабул иткәндә түбәндәге критерийлар исәпкә алына:

- халык дружинасы әгъзаларының массакүләм чаралар үткәрүдә катнашуы;

- дежурлыкка даими чыгу;

- административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау, хокук саклау органнарына җинаятьләрне ачуда ярдәм күрсәтү;

9. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш уздырылган көннән өч көн эчендә рәис, секретарь һәм комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«__» ________ 2018 ел, N ____
карарына 2 нче кушымта

**"Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен" премиясен бирү буенча комиссия составы**

Галимуллин И.Ә. - комиссия рәисе, ТР Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе

Нәбиуллин И.М. - комиссия секретаре,
Башкарма комитет җитәкчесенең мобилизация эшләре һәм ГХ штабы буенча ярдәмчесе

Гарифҗанов Р.И - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, Арча муниципаль районы ДНД штабы башлыгы

Гайнетдинов Ф.Ф. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча идарәсенең ПДН участок уполномоченныйлары бүлеге җитәкчесе

Габидуллин И.М. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча полиция башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча)

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«__» ________ 2018 ел, N ____
карарына 3 нче кушымта

"Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе бирүгә тәкъдим итү

Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме____________________________________
Туган елы, ае, көне ________________________________________________________
Яшәү адресы _______________________________________________________
Халык дружинасы отрядының исеме һәм эш урыны _______________________
________________________________________________________________________
Татарстан Республикасында халык дружиналары һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр реестрына кандидатны кертү датасы (саны, ай, ел)_Место работы, должность ______________________________________________________
________________________________________________________________________
Премияне бирүгә тәкъдим ителгән соңгы ел өчен конкрет казанышлар күрсәтелгән характеристика:
Халык дружинасы әгъзаларының массакүләм чаралар үткәргәндә катнашуы:________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
дежурга чыгу даимилеге:_______________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау:_____________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
хокук саклау органнарына җинаятьләрне ачуда ярдәм күрсәтү:________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
Башка
казанышлар:_____________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Халык дружинасы отряды командиры ___________________
__________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Мөһер урыны
«_____» ________________ 20___ел